1918 елнын 29 октябре конне I Ботенроссия эшче һәм крестьян яшьләре берлеге съездында Россия яшьләре коммунистик берлеге (РКСМ) оештырылган. Ул 1924 елда - Ленинныкы, ә 1926 елдан Ботенсоюз яшьләр берлеге (ВЛКСМ) итеп vзгәртелә. Комсомол мәктәбен берничә буын яшьләр vткән. СССРнын торле почмак-ларында гигант тозелешләрдә башлап йорvчеләр комсомоллар булдылар. Комсомоллар кулы белән зур заводлар тозелде, шәһәрләр калкып чыкты, Боек Ватан сугышы елларында да комсомол яшьләр, геройларча сугышып, зур батырлык vрнәкләре кvрсәттеләр. Боларнын барысы да бvген тарихта калды.   Әмма, ничек кенә булмасын, ул vзенен элекке идеологик мәгънәсен инде югалтса да, 29 октябрь - Комсомол туган кон яшьлеген комсомол белән бәйләгән һәркемнен, гомумән, безнен барыбызнын да ин кvнелле бәйрәмнәренен берсе булып кала бирә, чонки анын горурланырлык кешеләре һәм эшләре бар. Яшьлекнен хезмәт романтикасы ул.

Илебезнен торле почмакларында тосле, Инсар районы vзәгендә, 1970 елны Рязань заводынын электрон приборлар филиалы эшли башлый, бvген ул инде АО «Неон». Яна эшне башлап жибәрvчеләр арасында топ масса комсомоллар булды. Алар торле-торле ярышларда катнаштылар. ВЛКСМнын 70-еллыгы унаенннан билгеләнгән ярышта беренчелектә нәкъ шул завод филиалы комсомоллар бригадасы иде. Анда бик кvп татар милләтле яшьләребез эшләде һәм шул жинvдә зур олеш керттеләр. Авыл хужалыгында да жинvчеләр рәтендә шул ук комсомоллар булды. Мәсәлән, Инсар районы Федосеенко исемен йорткән колхоз комсомолы Зариф Бикмаев беренчелекне яулаган кеше. Әйтеп китәргә кирәк, торле елларда торле районнарда һәм шәһәрләрдә андый татар милләтле алдынгыларыбыз байтак булды.

Нурия Хафиз кызы Дулатова гомере буе Темников районы Тархан урта мәктәбендә

татар теле һәм әдәбиятын укыткан хөрмәтле укытучы. Укучылары аны ярата, әти-әниләре һәм якташлары хөрмәт итә. Нурия Хафиз кызы комсомол рухында тәрбияләнгән, комсомол эшендә vзе укыган мәктәптә дә, югары уку йортында да, укыткан мәктәбендә дә актив катнашкан кеше. Ул: «Әлеге истәлекле конгә хормәт белән карыйм, ул минем очен әһәмиятле, чонки ил тарихынын сәхифәсе булып тора. Анын һәр этабы безнен яшьлек белән бәйле.
Комсомол булу зур дәрәжә иде, ул оешмага керvчеләргә пионер галстугын салдырып, комсомол значогын тагалар, ВЛКСМ дип язылган иде анда. Искә ала торган хатирәләр байтак, укырга керvгә октябрят буласын, аннан зурлап пионерга алалар, кызыл галстук тагып козге алдында әйләнv зур горурлык. Син - пионер. Әйбәт уку, жәмәгать эшләрендә катнашып очып йорvләр. Һәр унышынны кvреп соенгән укытучылар... һәм сине лаеклы булсан, комсомолга алалар. Павел Корчагиннар vрнәк. Идеология бар вакыт. Комсомол исемен лаеклы йортvчеләр партиягә кабул ителәләр, коммунист буласын! Менә шундый заманда яшәп, шулай тәрбияләнгән балалар без».

- Мин дә комсомол идем, ди әнгәмәдәшем Рузаевка районы Татар Пешләсе авылында гомер итvче, хормәтле тимер юл хезмәткәре Айрат Раис улы Саляев. - Комсомол булу бик жинел генә башкарыла торган эш тvгел иде, монын очен ныклап әзерләнергә кирәк. ВЛКСМ дип аталган әлеге оешманын уставы бар иде һәм комсомоллар рәтенә басучы аны ятларга тиеш иде, комитет әгъзалары каршында шактый гына сорауларга жавап та бирдек. Сораулар торле булды. «Комсомолга ни очен керәсен?» кебек сораулар ин жинеле, син ана тиз жавап бирәсен: «Коммунизм тозvдә vземнән олеш кертv очен!» Хәзергеләргә бу бәлки мәзәк булып тоеладыр, әмма ул чорда комсомолга керә алмау хурлык, тvбәнлек санала иде. Уставны белv генә сине комсомол ясамый әле, укуы, тәртибе начар булганнарга, милициядә учетта торучыларга бу оешмага керv бәхете тими иде. Ә ВЛКСМ әгъзасы булмаганнарга юлларнын да кvбесе бикле. Юкка гына узган гасырнын 70нче елларында комсомоллар саны 36 миллионга чаклы житмәгән шул. Бvгенгә хәтле әлеге рекордны доньядагы бер генә яшьләр оешмасынын да кабатлый алганы юк әле.
Идеологик мәгънәсе югалса да, 29 октябрь - Комсомол туган кон. Яшьлеге ВЛКСМ белән бәйле кешеләрнен ин якын бәйрәме булып кала.

Наилә Насырова